Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы утырышы

**Карар № 81**

Түбән Бәрәскә авылы 27 октябрь 2023 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китергән яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау хакындагы 2016 нчы елның 23 нче апрелендә кабул ителгән 26 нчы номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 2 өлеше һәм Әтнә районы Прокуратурасы тарафыннан 2023 елның 18 августындагы 0208-02-2023/Прдп 254-23-20920010 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китергән яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә раслау хакында”гы Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 23 нче апрелендәге 26 нчы номер белән расланган карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы «(Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе) (кирәклесен сайларга)» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) 1 нче кушымта нигезендә форма буенча төзелгән хәбәрнамәне җибәрә».

1.3. 6 пунктның беренче абзацындагы «муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 7 пунктның өченче абзацындагы «яисә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.5. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Комиссия «Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 30 июлендәге 111 номерлы Әтнә район Советы тарафыннан расланган Комиссия турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәләрне карый һәм алар буенча карарлар кабул итә» һәм кабул ителгән карарны муниципаль район башлыгына, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисенә җибәрә.

1.6. 9 пункттагы «муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.7. 10 пункттагы «яисә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.8. 11 пункттагы «муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.